

# Йолдыз

Издательский дом
МБДОУ Детский сад №11



Ежеквартальная газета
для детей и их родителей

**В этом выпуске мы продолжим актуальную на сегодняшний день, тему «Развитие речи у дошкольников».**

**Читайте в номере:**

Советы родителям по развитию речи детей раннего возраста. с 2
Баланы ике телгә ничек өйрәтергә? с 3
Идел буе халыкларының милли бәйрәмнәре с 4
Психолог киңәшләре Адаптация үтүне ничек җиңеләйтергә? с 5

***Речь ребенка развивается под влиянием взрослых и в значительной мере зависит от достаточной речевой практики, нормального социального и речевого окружения, от воспитания и обучения, которые начинаются с первых дней его жизни. Предлагаем обратить внимание на следующие рекомендации…***

***Подробнее на следующей странице***

## *Детский календарь праздников*









## Советы родителям по развитию речи детей раннего возраста.



...Разговаривайте со своим ребенком во время всех видов деятельности: во время приготовления еды, уборки, одевания-раздевания, игры, прогулки. Рассказывайте о том, что вы делаете, видите, что делает и видит ребенок.

Разговаривайте, используя правильно построенные фразы, предложения. Ваше предложение должны быть на несколько слов длиннее, чем у ребенка.

Задавайте ребенку открытые вопросы. Стимулируйте ребенка использовать несколько слов для ответа. Например спрашивайте «Что делают дети?» вместо «Дети играют?».

Выдерживайте паузу, чтобы у ребенка была возможность говорить и отвечать на вопросы.

Слушайте звуки и шумы. Спросите «Что звучит?». Это может быть лай собаки, шум ветра, мотор машины.

Рассказывайте ребенку короткие рассказы и истории. Затем помогите ребенку рассказать эту же историю Вам или кому-то еще.

Занимайтесь с ребенком в игровой форме. Работа с ребенком должна активизировать речевое подражание, формировать элементы связной речи, развивать память, вним

Важно уже в раннем возрасте обратить внимание на речевое развитие ребенк а не дожидаться, когда он «сам заговорит».

**В промежутке от года и до 5-6 лет закладывается та база, на котором в дальнейшем ребенок будет строить всю свою жизнь в социуме.**

**Не стесняйтесь беседовать с ребенком!**

Татарчалы-русчалы сөйләм бүген күп кенә гаиләләрнең көндәлек тормышына кергән. Баланы икенче телгә өйрәтү өчен иң кулай вакыт – аның беренче телне өйрәнгән чагы, “бер телле”ләр белән чагыштырганда, иҗади яктан күбрәк үсеш кичерә. Моннан тыш, аларның яңа мәгълүматны яхшырак үзләштерүе һәм тапкыррак булуы күзәтелә дип саный дөнья күләмендә дан казанган педагогия белгечләре.

# Балагызның ике телдә дә яхшы сөйләшүен теләсәгез, түбәндәге киңәшләргә колак салыгыз:

**Соңламагыз**. 2-3 яшьлек чагында бала аерым сүзләрне генә түгел, тулаем сөйләм рәвешен аңына “сеңдерә”. Икенче телне никадәр иртә өйрәтә башласагыз, балага аны исендә калдыру шулкадәр җиңел булачак. “Төрле фонетик әйтелешне аңлап, аны кабатларга өйрәнү процессы 3 яшькә кадәр генә актив бара. Моннан соң без аерым бер авазларны дөрес ишетеп кабатлау мөмкинлеген югалта башлыйбыз, — ди Нью-Йорктагы “Language” балалар үзәгенең директоры Франсуа Тибо. — Шуңа күрә хәтта мультфильм, видео һәм җырлардан ишеткән табышлы мәгълүмат яңа телне өйрәнү өчен көчле нигез булып тора, баланың аны алга таба яхшы үзләштерүен күпкә җиңеләйтә”.

**Бер үк сүзне берьюлы ике телдә өйрәтегез.** Балага яңа сүзне өйрәткәндә, аның берьюлы ике телдә ничек әйтелгәнен күрсәтегез. Бу очракта сабый бер үк әйбернең ике төрле атамасы барлыгын аңлап калачак. Сүзләрне берьюлы ике телдә әйтүне гаиләгездә гадәткә кертергә тырышыгыз.




**Ситуацияне адекват бәяләгез.** Күп кенә ата-ана ике телдә өйрәтү аркасында баланың теле озак ачыла дип санаса да, бу — ялгыш фикер. Сабыегыз, яшьтәшләренә караганда, бер телдә азрак сүз белсә дә, аның ике телдә дә белгән сүзләренең гомуми саны, гадәттә, барыбер күбрәк була. Ә калган сүзләрне ул үсә барган саен тиз рәвештә өйрәнәчәк.

**Кечкенә буталчыклардан курыкмагыз.** Ике тел сүзләрен бер җөмләдә бутап әйтү – бала өчен табигый хәл. Вакыт узу белән ул аларны бүлеп сөйләшергә үзе өйрәнәчәк.

# Психолог киңәшләре
# Адаптация үтүне ничек җиңеләйтергә?

* Беренче чиратта, үзегез тыныч булырга, тәрбиячеләргә ышанырга тиешсез. Әгәр дә бала каршында алдан кайгырып, “Ул анда нишләр инде, ашатырлармы, өшемәсме, кыерсытмаслармы?” дип, бәргәләнеп йөрсәгез, аның тиз генә өйрәнеп китүен көтмәгез дә.
* Вакытыгыз таләп итә икән, бераз кыска вакытлы төркемгә, берничә сәгатькә генә йөртегез. Бала бакчага йөрүне тынычрак кабул итә башлагач, тулы көнгә калдырырга мөмкин.
* Иртән баланы калдырып киткәндә, качып китү дөрес түгел. Саубуллашу моментын озакка сузу да сезнең файдага булмас. Сабыегызны кочаклап, яратып, төркемгә кертеп җибәрегез.



* Күз яшьләре, истерика — ул, гадәттә, әниләр кызгансын өчен тәгаенләнә. Баланы бакчага әти кеше илтсә, тагын да яхшырак. Артык эмоцияләргә бирелмәү адаптацияне тизләтәчәк.
* “Әгәр бакчада еламый гына калсаң, озак итеп мультфильм карарсың” яисә “Үзең теләгән уенчыкны алып бирәм” дип шартлар куярга ашыкмагыз. Бик тиздән кечкенә кеше сезнең бу гадәтегездән файдалана башлаячак.

* Бакчадан чыккач көннең ничек үтүе турында сөйләшүләр дә файдалы. Үзегезнең бакчага йөргән чагыгызны, нинди ботка яратуыгызны, тәрбияче апаларыгызны искә төшереп, балага тик уңай моментлар турында сөйләгез.
* Балага бакчага йөрүнең зур горурлык булуын аңлатыгыз. Әйтик, картәти-картәниләренә, абый-апаларына аның бакчадагы уңышлары турында мактап сөйләгез.
* Бакчага барырга үгетләгәндә, “Сине тәрбияче апаларың бик ярата, алар сине көтә”, “Син булмасаң, дустыңа күңелсез булачак” дип кабатлаудан кыенсынмагыз. Бала үзенең анда кирәк булуын аңларга тиеш.
* Иң яраткан уенчыгын бакчага алып бару — монысы четерекле мәсьәлә. Еш кына нәкъ шул уенчык башкаларга да кирәк булып чыга. Аннары елаш, тарткалаш башлана. Шуңа күрә сабыегызны бакчада булган берәр йомшак аюга, машинага “ияләштерегез”.

# Идел буе халыкларының милли бәйрәмнәре

## ТРОЙСЫН – ЯФРАК БӘЙРӘМЕ



Тройсын – керәшен татарларының яфрак бәйрәме ул. Бу бәйрәм агачларның яфрак ярган, матурланган, табигатьнең яшәргән, җанланган чагына туры килә. Тройсын – җәйне каршылау бәйрәме ул. Бу яфрак бәйрәменә кадәр җирдән үлән йолкырга да, агач яфракларын өзәргә дә, су коенырга да ярамый. Җир иминлеге дип, табигатьне саклаганнар олылар.

Керәшен татарлары Яфрак бәйрәмендә җир һәм су ияләренең күңелен күргәч кенә, җирдән үлән яки чәчәк өзәргә ярый, диләр. Бу көнне егетләр-кызлар Тройсын җырларын җырлап, авыл урамына ямьнәр кертеп, болынлыкка җыелганнар. Бергәләп җырлап-биеп күңел ачканнар, халык уеннары уйнаганнар. Бәйрәмдә бер-берсенә күгебез аяз, җиребез имин булсын иде, дигән теләкләр теләгәннәр һәм су буена төшеп, матур теләкләре юш булсын дип, каен яфракларын суга салганнар. Тройсынны озатканнар.

Сабантуй бәйрәме – татар халкының иң олы бәйрәмнәренең берсе. Ул – хезмәт һәм дуслык бәйрәме.Сабан туе – ул һәркемнең көтеп алган изге бәйрәме. Минем бик күп Сабантуйларда булганым бар. Иң элек Сабантуй үткәрү өчен мәйдан әзерлиләр. Безнең авылда Сабантуй елга буендагы яшел чирәм белән капланган иңкүлектә үткәрелә. Якында гына челтерәп аккан чишмәсе дә бар.Иртәгә Сабантуй буласы көнне авыл яшьләре, урам буйлап гармуннар уйнап, җырлап-биеп, хуҗабикәләрдән, яшь киленнәрдән Сабан туе өчен махсус әзерләнгән бүләкләр җыеп, халыкны бәйрәмгә чакырып йөриләр. Бу «Сөлге җыю» дип атала.Икенче көнне матур итеп бизәлгән мәйданга бәйрәмчә киенгән халык җыела. Мәйдан уртасында батырлар көч сынаша. Җиңүчеләрне тәкә һәм кыйммәтле бүләкләр көтә.




## Карга боткасы



Татар халкының яз көне үткәрелә торган бәйрәмнәренең берсе - "Карга боткасы" ("Воронья каша") тора. Борын-борын заманда кешеләр ни өчен яз булганын белмәгәннәр, ди. Алар язны җылы яклардан кара каргалар алып килә икән дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп, сулар ага башлагач, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны “карга боткасы” дип атаганнар. Бу көнне балалар йорттан йортка кереп ярма, йомырка, шикәр, май, сөт җыйганнар һәм халыкны бәйрәмгә чакырганнар. Халык авылның иң биек урынына җыелып, учак яккан, казанда ботка пешергән. Аланда уйнаганнар, җырлаганнар, күңел ачканнар. Ахырдан ботка ашый торган булганнар. Ботканың бер өлеше тыныч тормыш теләп җиргә, икенчесе – җирдәге тереклекне сакласын дип, суга һәм өченчесе – кояшлы көннәр күбрәк булсын, вакытында яңгырлар яусын дип күккә , дүртенчесе- язны алып килгән өчен кара каргаларга бирелгән. Шуннан соң калган ботканы кешеләр үзләре бүлешеп ашаганнар. Кешеләр таралышкач, кара каргалар алар калдырган ботканы очып килеп ашаганнар.